**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күл Черкене авыл җирлегенең Лашчы тимер юл разъезды поселогы гражданнар җыены карары**

21 март 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күл Черкене авыл җирлегенең Лашчы тимер юл разъезды поселогында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күл Черкене авыл җирлегенең Лашчы тимер юл разъезды поселогында гражданнары җыенының 2023 елның 17 ноябрендәге 1нче номерлы карарының 2 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:.

“2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- коймалар төзү, төзекләндерү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү;

- урам яктырту җайланмалары урнаштыру;

- торак пункт территориясен төзекләндерү (мәчет янындагы территориядә өскорма төзү);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.”.

2. Җыен нәтиҗәләрен Күл Черкене авыл җирлегенең Лашчы тимер юл разъезды поселогында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Күл Черкене авыл җирлеге башлыгы _________ М.К. Истиев

Халык җыены секретаре _________ И.Р. Гибадуллина